| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СТАРОЧЕКАЛДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧЕКАЛДА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.02.2024 Иске Чекалда авылы № 6

«2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге җирләрен файдалану һәм саклау» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 07.11.2022 елның 16 номерлы Иске Чекалда авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 21 июлендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге җирләрен файдалану һәм саклау» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 07.11.2022 елның 16 номерлы Иске Чекалда авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 2 бүлекнең 2 абзацында «авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфракның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту өчен» сүзләрен «җирләрнең үзлекләрен яхшырту, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу өчен» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының веб-адрес буенча хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 01.03.2024 елдан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Исполнительный комитет Старочекалдинского сельского поселения Агрызского муниципального района Республики Татарстан

Җитәкчесе П.М.Королев